**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул.Советская, д.6, с.Старое Кадеево, 423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 6 йорт, Иске Кади авылы, 423117

тел./факс (84396) 3-13-25 email: Skad.Cmn2@tatar.ru

19.04.2021 № 10

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты ягыннан капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында " 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 3.1 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «6) административ - эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), шулай ук күп фатирлы йортлар, торак йортлар (территорияләрне комплекслы үстерү турындагы килешү нигезендә мондый йортлар төзү очракларыннан тыш) төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү)».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.В.Мөктасимов